# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Николаевка авыл җирлеге Рус Каран торак пунктында
гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында

29.11.2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 29.11.2023гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлеге Рус Каран торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ яшьтәге кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә сез ризамы, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр, мобилизацияләнгән гранданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлтергә:

1)Рус Каран торак пунктында юлларын грейдирлау (килешү буенча эш өчен түләү), (урам яктырту өчен фотореле сатып алу һәм урнаштыру, энергия саклаучы яктырткычларны һәм урам яктырту лампаларын алыштыру, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Рус Каран торак пунктында килешү буенча урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү;

3) Рус Каран торак пунктында насос сатып алу, су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, су күтәрү манарасын ремонтлау (килешү буенча эш өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 50 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 27 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде 27 халык җыенында катнашучылар;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлегенең Рус Каран торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Николаевка авыл җирлеге Рус Каран торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ яшьтәге кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә сез ризамы, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр, мобилизацияләнгән граҗданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш,һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлтергә:

1)Рус Каран торак пунктында юлларын грейдирлау (килешү буенча эш өчен түләү), (урам яктырту өчен фотореле сатып алу һәм урнаштыру, энергия саклаучы яктырткычларны һәм урам яктырту лампаларын алыштыру, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Рус Каран торак пунктында килешү буенча урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү;

3) Рус Каран торак пунктында насос сатып алу, су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, су күтәрү манарасын ремонтлау (килешү буенча эш өчен түләү).

3. Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Николаевка авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән - http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында - http://pravo.tatarstan кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең әлеге карарынТатарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Николаевка авыл җирлеге
башлыгы урынбасары В.А.Липин